Заявка формасы

| Белем бирү оешмасы | Катнашучының Ф.И.А.и., сыйныфы | Җаваплы җитәкченең Ф.И.А.и., эл.почтасы, телефоны | Мәктәп этабында катнашучылар саны |
|---|---|---|---|
| | | | |

11. II этапта катнашучыларга түбәндәгеләрне тапшырырга кирәк:

1) тәкъдим ителгән темаларның берсенә презентация. Презентацияләрнең темалары:

- «Сезнең тормыш - үзе батырлык» (КамАЗ тарихында танылган кешеләр);
- «Янып калсын гомерең, маяк булып...» (Муса Җәлилнең тууына 120 ел);
- «Йөрәкләрдә Тукай эзләре, күңелләрдә Тукай сүзләре» (Габдулла Тукайның тууына 140 ел);
- «Җиде яктан җыелып килгән җиде ятның язмышларын җыйды данлы КамАЗ» (халыклар дуслыгы - шәһәребезнең иң зур байлыгы).

Беренче слайд түбәндәгеләр күрсәтелгән мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

- белем бирү оешмасының исеме;
- конкурсның исеме;
- авторның фамилиясе, исеме;
- конкурс эшенең (презентациянең) темасы.

Презентация заявка белән бергә 2026 елның 10 мартына кадәр срокта түбәндәге электрон адреска җибәрелә: odmoo.saifullina@yandex.ru

2) иҗади визитка. Иҗади визиткаларны карау «14 нче балалар-яшүсмерләр үзәге» МАӨББУда үтәчәк (Чулман-88 (44/16), каб. 202). Чыгышларның датасы һәм графигы мәгълүмати хат итеп белем бирү оешмасының электрон адресына өстәмә рәвештә җибәрелә.

12. Презентацияләрне бәяләү критерийлары:

1) эчтәлек өлеше:

- эшнең презентация темасына туры килүе;
- эчтәлекле булуы;
- мәгълүматның төгәл һәм кыска булуы;
- креативлык (идеянең яңа, оригиналь булуы);
- уникальлек (плагиат булмау);
- практик кыйммәте;

2) техник өлеш:

- эш PowerPoint программасында башкарылган;
- бизәлешнең бердәм стиле;
- слайдларда төрле объектларны файдалану;
- текст җиңел укыла, фон текст һәм график файллар белән тәңгәл килә;
- анимация эффектлары максатчан файдаланылган;
- презентациядә слайдлар саны 15 тән артмый.

13. Иҗади визитканы бәяләү критерийлары:

1) татар телен белү;
2) сәхнәдә үзен тота белү;
3) актерлык осталыгы һәм сәхнә сөйләме дәрәҗәсе;
4) индивидуальлек;
5) музыканың, җырның, шигырьнең эчтәлеге балалар яшенә туры килү;
6) концерт номерларының камиллеге;
7) костюмнарның эстетик ягы.

